**Совет Нижнеураспугинского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге Советы**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**03 июнь 2019 ел** **№187**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге бюджетыннан чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында.

Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге башлыгы мәгълүматын тыңлаганнан һәм караганнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 мартындагы "Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар беләнт тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" 233нче Карары, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Советының 2010 елның 26 апрелендә кабул ителгән 379 номерлы «Яшел Үзән муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" гы карары нигезендә, Т.Урысбага авыл жирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге бюджетыннан чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталындан (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Түбән Ураспуги авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Ураспуги авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге башлыгына йөкләргә.

**Т.Урысбага авыл жирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Х.Х.Сибгатуллин**